КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 декабрь г.Казань № 1319

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы; 2022 ел, 15 март, 240 нчы; 2022 ел, 22 июль, 707 нче, 2022 ел, 16 сентябрь, 1009 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның унөченче абзацында «җитештерү» сүзенә кадәр «ачык грунтта яшелчә культуралары» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Үсемлекчелек, бәрәңге һәм орлык бәрәңгесен, техник киндерне һәм (яки) озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «җитештерү» сүзенә кадәр «ачык грунтта яшелчә культуралары» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта:

беренче абзацта «җитештерү» сүзенә кадәр «ачык грунтта яшелчә культуралары» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасын өстәргә:

«д) агротехнологик эшләр комплексын уздыруга - ачык грунтта яшелчә культуралары биләгән чәчү мәйданының 1 гектарына ставка буенча (алга таба - ачык грунтта яшелчә культураларын җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм итү).»;

җиденче абзацта «әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында» сүзләрен «әлеге пунктның «а», «б» һәм «д» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге пунктның «а», «б» һәм «д» бүлекләрендә күрсәтелгән юнәлешләр буенча, агротехнологик эшләр башкарганда чәчүгә селекция казанышларының дәүләт реестрына кертелгән авыл хуҗалыгы культуралары, сортлары яисә гибридлары орлыклары кулланылган очракта, шулай ук мондый орлыкларның сортлы һәм чәчү сыйфатлары ГОСТ Р 52325-2005, ГОСТ Р 58472-2019, бәрәңге өчен ГОСТ 33996-2016, яшелчә культуралары өчен ГОСТ Р 32592-2013, ГОСТ 30106-94;»;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

7 пунктта:

бишенче абзацта «агымдагы елның 1 сентябренә кадәр» сүзләрен «заявка биргән көнгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «(агымдагы елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча) сүзләрен төшереп калдырырга;

егерме өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә субсидия алу өчен сайлап алуда катнашучылар өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшыралар:

ачык грунтта яшелчә культураларын сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныкланган һәм «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы белән килештерелгән, агымдагы финанс елы уңышына бәйле чәчүлек мәйданнары турында ирекле рәвештә мәгълүмат, гектарларда ;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазен.

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныклана.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.»;

11 пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

16 пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Бу Тәртипнең 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_а$) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_а = P \times S + P_{стр} \times S \times 1,2 + P_{фг} \times S \times 2,0,»;$$

унөченче абзацта «агымдагы елның 1 сентябренә кадәр» сүзләрен «заявка биргән көнгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бу Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_б$) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_б = P_{тг} \times S,»;$$

алтынчы абзацта «агымдагы елның 1 сентябренә кадәр» сүзләрен «заявка биргән көнгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Бу Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_в$) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_в = P_{лен} \times S,»;$$

алтынчы абзацта «агымдагы елның 1 сентябренә кадәр» сүзләрен «заявка биргән көнгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктта:

беренче һәм икенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Бу Тәртипнең 1 пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_г$) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_г = (P_{ос} \times S_{ос}) + (P_{эс} \times S_{эс}),»;$$

сигезенче абзацта «агымдагы елның 1 сентябренә кадәр» сүзләрен «заявка биргән көнгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $19^1$ пункт өстәргә:

«19[1]. Бу Тәртипнең 1 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ($W_{д}$) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{д} = P_{ов} \times S_{ов},$$

монда:

$P_{ов}$ - субсидия алучының быелгы финанс елы уңышына ачык грунтта яшелчә культуралары сортлары һәм (яисә) гибридлары белән бирелгән чәчү мәйданы, гектар;

$S_{ов}$ - субсидия ставкасы, субсидия алучы 1 гектар чәчүлек мәйданына агымдагы финанс елы уңышы өчен ачык грунтта яшелчә культуралары сортлары һәм (яисә) гибридлары утыртылган, 25 000 сум исәбеннән.

Ачык грунтта яшелчә культураларын җитештерүне үстерү өлкәсендә ярдәм итүгә субсидияләр алучы тарафыннан бирелә торган субсидия күләме, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча дәүләт агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карары белән расланган федераль бюджеттан финанслана торган Федераль бюджеттан финанслана торган яшелчәләр җитештерүне үстерүне стимуллаштыруга юнәлдерелгән чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе нигезендә ачык грунтта яшелчә культураларын җитештерүгә, сатуга һәм (яисә) үзендә эшкәртүгә бәйле заявка биргән көнгә кадәр, субсидия алынган чыгымнарны тотып, фактта тотылган чыгымнар күләменнән артып китә алмый.

Әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча бирелә торган субсидияне алучылар тарафыннан белдерелгән субсидиянең гомуми күләме Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Министрлык арасында төзелгән «Крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, ачык грунтта яшелчәләрне тулаем җыю» субсидиясеннән файдалану нәтиҗәләре буенча үсемлекчелек һәм терлекчелекнең аерым тармаклары буенча авыл хуҗалыгы җитештерүенә ярдәм итүгә Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында килешүдә Татарстан Республикасы бюджетынабилгеләнгән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре күләменнән артып киткән очракта субсидия алучыга бирелергә тиешле субсидия күләме ($W_{ков}$) Министрлык тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{ков} = W_{д} \times K_{ов},$$

монда:

$K_{ов}$ - түбәндәге формула буенча билгеләнә торган төзәтү коэффициенты:

$$K_{ов} = V_{ов} / \sum_{д=1}^{n} W_{д},$$

монда:

$V_{ов}$ - Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Министрлык арасында төзелгән «Крестьян (фермер) хуҗалыкларында, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, ачык грунт яшелчәләрен тулаем җыю» субсидиясеннән файдалану нәтиҗәләре буенча үсемлекчелек һәм терлекчелекнең аерым ярдәмче тармаклары буенча авыл хуҗалыгы җитештерүенә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү турында килешүдә билгеләнгән Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләре күләме;

n - әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «д» подпункында күрсәтелгән юнәлеш буенча субсидия алучылар саны;

д - әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «д» пунктчасында күрсәтелгән юнәлеш буенча субсидия алучылар.»;

20 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:»әлеге Тәртипнең 1 пунктындагы «д» пунктчасы нигезендә - субсидия бирү турындагы килешүдә каралган ачык грунтта яшелчәләрнең тулаем җыемының планлаштырылган күләмнәрен тәэмин итү - субсидия бирү елның 31 декабренә кадәр, тонна.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин